«Раслыйм»
Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясен планлаштыру проектлары һәм территорияне межалау проектлары буенча комиссия рәисе урынбасары

_____________________ П.Б. Емельянов

№ 3
2022 елның 13 октябре

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясен планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында
**БӘЯЛӘМӘ**

Чистай муниципаль районы башлыгының «Территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча ачык тыңлауларны билгеләү турында» 2022 елның 1 октябрендәге 61 номерлы карары белән билгеләнгән ачык тыңлаулар 2022 елның 13 октябрендә 10.00 сәгатьтә Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының зур залында түбәндәге адрес буенча узды: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Чистай шәһәре, Бебель урамы, 129 нчы йорт.

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы территориясен планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты буенча 2022 елның 13 октябрендәге 3 номерлы ачык тыңлаулар үткәрү беркетмәсе.

**Ачык тыңлаулар предметы:**

Территорияне планлаштыру проектын һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында «Казан-Оренбург»-Татар Талкышы автомобиль юлын реконструкцияләү объекты буенча территорияне межалау проектын карау турында «Главтатдортранс» ДКУ мөрәҗәгате буенча.

**Карар итү:**

1. Территорияне планлаштыру проекты һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында «Казан-Оренбург»-Татар Талкышы автомобиль юлын реконструкцияләү объекты буенча территорияне межалау проекты буенча ачык тыңлауларны узган дип санарга.
2. Территорияне планлаштыру проектын һәм территорияне межалау проектын хупларга.
3. Комиссия беркетмәсен һәм бәяләмәсен Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.
4. Әлеге бәяләмәне ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Комиссия секретаре: Хөснетдинов А.Н.